ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«20 гыйнвар 2026 ел** **№ 30**

**Җирле, районара, республика дәрәҗәсендәге физкультура-савыктыру, спорт һәм күнегүләр чараларын уздыруга чыгымнар нормаларын раслау турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасының физкультура чараларының һәм спорт чараларының календарь планына кертелгән рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын (шул исәптән әһәмиятле халыкара рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын) уздыруга чыгымнар нормаларын раслау турында” 2025 елның 2 декабрендәге 1031 номерлы карары нигезендә, җирле, районара дәрәҗәдәге физкультура-савыктыру, спорт һәм күнегүләр үткәрүгә чыгымнар нормаларын тәртипкә салу максатында Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта итеп бирелә торган:

- физкультура-савыктыру, спорт һәм күнегүләр үткәргәндә спортчыларны, тренерларны һәм белгечләрне туклану белән тәэмин итү чыгымнары нормаларын (1 нче кушымта);

- физкультура-савыктыру, спорт һәм күнегүләр үткәргәндә спортчыларны, тренерларны һәм башка катнашучыларны яшәү белән тәэмин итү чыгымнары нормаларын (2 нче кушымта);

- спорт чараларына хезмәт күрсәткән өчен спорт хөкемдарларына түләү чыгымнары нормаларын (3 нче кушымта);

- төрле дәрәҗәдәге спорт чараларында катнашучыларны автотранспорт белән тәэмин итү чыгымнары нормаларын (4 нче кушымта) расларга.

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслау Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге буенча тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре исәбеннән башкарыла дип билгеләргә.

3. Арча муниципаль районы Башкарма комитетының "Җирле, районара, республика дәрәҗәсендәге физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм тренировка чараларының календарь планына кертелгән чыгымнар нормаларын раслау турында" 2024 елның 20 февралендәге 129 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Э.Ш. Вафинга йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы И.Ә.Галимуллин

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
башкарма комитетының
20 гыйнвар 2016 ел № 30
карарына
1нче кушымта

**Физкультура-савыктыру, спорт һәм күнегүләр үткәргәндә спортчыларны, тренерларны һәм белгечләрне туклану белән тәэмин итү**
**ЧЫГЫМНАРЫ НОРМАЛАРЫ**

| Спорт чаралары исемнәре | Бер кешегә көнлек чыгымнар нормасы, сумнар |
|---|---|
| 1. Массакүләм физкультура-спорт ярышлары һәм чаралары | 365гә кадәр |
| 2. Татарстан Республикасы чемпионатлары, беренчелекләре, кубоклары һәм аларга укыту-тренировка (тренировка) чаралары (спартакиадалар, Универсиадалар) | 700 гә кадәр |
| 3. Бөтенроссия ярышлары һәм аларга укыту-тренировка (тренировка) чаралары | 1300 гә кадәр |
| 4. Международные соревнования и тренировочные мероприятия к ним по неолимпийским и непаралимпийским видам спорта | 1300 гә кадәр |
| 5. Олимпия һәм паралимпия спорт төрләре буенча халыкара ярышлар һәм аларга әзерлек чаралары | 1300 гә кадәр |

Искәрмә:

1. Авырлыгы 90 килограммнан артык һәм (яисә) буе 190 см дан югары булган спортчыларга аерым очракларда әлеге кушымтада билгеләнгән нормалар каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә 50 процентка кадәр күтәрелергә мөмкин.
2. Спорт чаралары уздырыла торган урыннарда оешкан туклануны тәэмин итү мөмкинлекләре булмаганда, әлеге кушымтада китерелгән чыгымнар нормалары чикләрендә акча бирү рөхсәт ителә.
3. Спорт чараларын үткәргәндә спорт хөкемдарларының барлык категорияләре дә туклану белән тәэмин ителми, аларның хезмәтенә түләү әлеге карар белән расланган спорт чараларына хезмәт күрсәткән өчен спорт хөкемдарларына түләү чыгымнары нормалары нигезендә башкарыла.
4. Чараларны үткәрүче оешмалар бюджеттан тыш, иганәчелек акчалары, шулай ук гариза кертемнәре исәбеннән барлык категориядәге хөкемдарларга туклану өчен компенсация түләүләрен башкарырга хокуклы.

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
башкарма комитетының
20 гыйнвар [illegible] ел № 30
карарына
2нче кушымта

**Физкультура-савыктыру, спорт һәм күнегүләр үткәргәндә спортчыларны, тренерларны һәм башка катнашучыларны яшәү белән тәэмин итү ЧЫГЫМНАРЫ НОРМАЛАРЫ**

| Яшәү өчен торак пунктларның категорияләре исеме | Бер кешегә бер көнгә сумма, сум |
|---|---|
| 1. Мәскәү шәһәре, Санкт-Петербург шәһәре, Сочи шәһәре | 2500 гә кадәр |
| 2. Россия Федерациясе субъектларының административ үзәкләре:<br>Ерак Төньяк территориясенә кертелгән шәһәрләр, торак пунктлар | 2500 гә кадәр |
| 3. Россия Федерациясе территориясендәге башка шәһәрләр һәм торак пунктлар | 2000 гә кадәр |

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
башкарма комитетының
20 гыйнвар 2026 ел № 30
карарына
3нче кушымта

**Спорт чараларына хезмәт күрсәткән өчен спорт хөкемдарларына түләү**
**ЧЫГЫМНАРЫ НОРМАЛАРЫ**

| Хөкемдар вазыйфаларының аталышы | Хөкемдарлар категорияләрен исәпкә алып түләүләр күләме, сум | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | МК, ВК | 1К | 2К | 3К/Ю/С | Категориясез |
| Баш хөкемдар | 1490 | 1096 | - | - | - |
| Баш хөкемдар-сәркатип | 1490 | 1096 | - | - | - |
| Баш хөкемдар урынбасары, баш сәркатип | 1100 | 918 | 733 | - | - |
| Хөкемдарлар | 998 | 796 | 679 | 624 | 530 |
| Командалы уен спорт төрләре | | | | | |
| Уенның баш хөкемдары | 870 | 696 | - | - | - |
| Уенның баш хөкемдары ярдәмчесе | 635 | 547 | - | - | - |
| Инспектор (техник делегат, комиссар) | 679 | - | - | - | - |
| Хөкемдарлар ( бригада составында) | 515 | 484 | 445 | 406 | 359 |

Шартлы билгеләр:
МК – халыкара категорияле спорт хөкемдарсы;
ВК – Бөтенроссия категорияле спорт хөкемдарсы;
1К – беренче категорияле спорт хөкемдарсы;
2К – икенче категорияле спорт хөкемдарсы;
3К – өченче категорияле спорт хөкемдарсы;
Ю/С – яшь спорт хөкемдарсы.

Искәрмә:

1. Түләүләр күләме ярышларның бер көненә хезмәт күрсәтү өчен каралган, командалы уен спорт төрләреннән тыш, анда бер уенга хезмәт күрсәтү өчен түләүләр башкарыла (футбол, алкалы хоккей, баскетбол, волейбол, су полосы, гандбол, туплы хоккей, чирәмдәге хоккей, бейсбол, регби һ.б.).
2. Ярышларның әзерлек һәм йомгаклау этапларында баш хөкемдарга, баш хөкемдар-сәркатипга, баш хөкемдар урынбасарына һәм баш хөкемдар-сәркатип урынбасарына яшәү, эш өчен түләү өстәмә рәвештә 2 көнгә арта.
3. Хөкемдарлар коллегияләренең (бригадаларының) составы спорт төрләре буенча ярышлар уздыру турында расланган кагыйдәләр нигезендә билгеләнә.

4. Халыкара, бөтенроссия ярышлары, Татарстан Республикасы чемпионатлары һәм кубоклары уеннарын оештыруны һәм уздыруны тикшереп тору өчен Уеннарның төп чаралары өчен түләүле инспекторлар яисә техник делегатлар билгеләнергә мөмкин.

**Физкультура-савыктыру һәм спорт чараларының календарь планына кертелгән физкультура-савыктыру, спорт һәм күнегүләр чараларын уздыру чыгымнары нормалары турында**